**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с. Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ленин пр.,17 йорт, Актаныш ав.,423740

Тел. (85552) 3-44-22, факс (85552) 3-44-14, E-mail: aktanysh@tatar.ru, www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ　　　　　　　　　　　　　　　　　　КАРАР

____________　　　　ПР-246 14.11.2024　　　　№___

**«2025 елга «Актаныш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге балаларына өстәмә белем бирү оешмаларының туристлык-туган якны өйрәнү, экологик-биологик, хәрби-патриотик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурологик юнәлешле мәгариф оешмаларының һәм өстәмә белем бирүнең күппрофильле мәгариф оешмаларының норматив чыгымнарын раслау турында»**

«Мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Законының 99 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешенең 11 пункты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 31 декабрендәге 939 номерлы «Туристлык-туган якны өйрәнү, экологик-биологик, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм күппрофильле мәгариф учреждениеләре һәм өстәмә белем бирүнең күппрофильле мәгариф учреждениеләре балаларының өстәмә белем бирү учреждениеләрен финанслау нормативларын исәпләү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында»гы карары һәм «Актаныш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, «Актаныш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2025 елга расларга:

«Актаныш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге балаларына өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында туристлык-туган якны өйрәнү, экологик-биологик, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурологик юнәлешле мәгариф программаларын һәм «Актаныш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге балаларына өстәмә белем бирүнең күппрофильле мәгариф оешмаларын гамәлгә ашыруга кушымта итеп бирелә торган норматив чыгымнар;

балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында туристлык-туган якны өйрәнү, экологик-биологик, хәрби-патриотик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурологик юнәлешле мәгариф оешмаларында һәм балаларга өстәмә белем бирүнең 0,75 күләмендә күппрофильле мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыруга норматив чыгымнарга төзәтмәләр коэффициенты.

2. «Актаныш муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең финанс-бюджет палатасына тәэмин итәргә:

әлеге карарның 1 пунктында расланган, балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларының норматив чыгымнары нигезендә балаларга өстәмә белем бирү оешмаларын финанслау;

әлеге карарның 1 пунктында расланган, балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларының норматив чыгымнары гамәлдә булу чоры дәвамында, хезмәт законнарында һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла торган балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт хакын индексацияләү белән бер үк вакытта яңадан карау.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2025 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары Д.М.Әнвәровага йөкләргә.

Җитәкче Р.А.Ильясов

Расланган
«Актаныш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесе карары
«___» ______ 2024 №____ белән

**«Актаныш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге балаларына өстәмә белем бирүнең туристлык-туган якны өйрәнү, экологик-биологик, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурологик юнәлештәге балаларга өстәмә белем бирүнең күппрофильле мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыруга норматив чыгымнар**

| Өстәмә белем бирү программасының юнәлеше | Территориаль дислокация | Норматив чыгымнар, 1 укучыга елына сумнарда | | |
|---|---|---|---|---|
| | | укуның беренче елы | Укуның икенче елы | өченче һәм аннан соңгы уку еллары |
| Сәнгать-эстетик | авыл җирлеге | 8 680 | 16 074 | 19 289 |
| Физкультура-спорт | авыл җирлеге | 8 579 | 15 887 | 19 064 |
| Техник иҗат | авыл җирлеге | 8 984 | 16 636 | 19 963 |
| Туристлык-туган якны өйрәнү | авыл җирлеге | 8 781 | 16 261 | 19 514 |
| Экологик-биологик | авыл җирлеге | 8 781 | 16 261 | 19 514 |
| Хәрби-патриотик | авыл җирлеге | 8 781 | 16 261 | 19 514 |
| Социаль-педагогик | авыл җирлеге | 8 376 | 15 512 | 18 614 |
| Социаль-икътисади | авыл җирлеге | 8 376 | 15 512 | 18 614 |
| Табигый фәнни | авыл җирлеге | 8 781 | 16 261 | 19 514 |